| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2020 Мөрәле ав. №7

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2012 елның 30 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8.3 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

1.2. 19.1 пунктының 4 пунктчасында «(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга, мәгълүмат стендларында һәм

Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең http://muralin-kaybici.tatarstan.ru. веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Зиннәтуллин Р.Р.